КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 февраль г.Казань № 96

Питрәч муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Питрәч муниципаль районында урнашкан 0,7596 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:33:121412:971 кадастр саны белән энергетика объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, мәгълүмат, космик эшчәнлекне тәэмин итү җирләре, оборона җирләре, куркынычсызлыз һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчеререргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин